**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«14» 01 2025 ел Яр Чаллы ш. №3

16:39:021201:6063 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы уставы, Тукай муниципаль районы авыл җирлекләренең җирдән файдалану һәм җир төзелеше проектларын һәм кагыйдәләрен әзерләү буенча ведомствоара комиссиянең 2024 елның 10 декабрендәге 8 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 16:39:021201:6063 кадастр номерлы җир кишәрлегенең «Торак төзелеше өчен, сәүдә объектлары (сәүдә үзәкләре, сәүдә-күңел ачу үзәкләре (комплекслары)» рөхсәт ителгән төп файдалану төрен «Автомобиль юу урыннары», «Автомобильләр ремонтлау» шартлы рөхсәт ителгән төргә үзгәртү проекты буенча халык тыңлауларын билгеләргә.
2. Халык тыңлауларын оештыручы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына җирле үзидарә турында, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар нигезендә халык тыңлауларын оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.
3. Халык тыңлауларын үткәрү 2025 елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиеш, дип билгеләргә.
4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) «Документлар/Иҗтимагый һәм халык тыңлаулары» битендә урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р. Хәбибуллинга йөкләргә.

Район Башлыгы вазифаларын башкаручы Р.И. Закиров